**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет**
**Сухояшского сельского поселения**
**Азнакаевского муниципального района**

С.Большой Сухояш, ул.Советская 32,
Азнакаевского муниципального района,
423325 Тел. (факс) (85592) 9-80-38
Suho.Azn @tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**Сукаеш авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

Зур Сукаеш авылы, Совет урамы,32,
Азнакай муниципаль районы, 423325
Тел.(факс)(85592) 9-80-38
Suho.Azn @tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «01» июля 2024 г №14

## Авыл җирлеге Башкарма комитеты карары

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2013 елның 31 мартындагы 17 номерлы «Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмалар һәм территорияләр чикләрен билгеләү турында»гы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

«Алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшәдәге территорияләрнең чикләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү һәм алкоголь продукциясен ваклап сату кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 23 декабрендәге 2220 номерлы карары, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2013 елның 31 мартындагы 17 номерлы карарына Азнакай шәһәр прокуратурасының 2024 елның 24 апрелендәге 02-08-02-2024/Прдп299-24-20920040 номерлы протестын карап, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы  Сукаеш авыл җирлеге Башкарма комитетының  2013 елның 31 мартындагы 17 номерлы «Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмалар һәм территорияләр чикләрен билгеләү турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык З.Җ.Закирова